МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

22.08.2022 Казан ш. № 2447-р

Газ бүлү челтәренең (газүткәргечнең) саклау зоналарын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында” 19.12.2015 № 3233-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында», 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ әзерләгән документациягә туры китереп, «Фонд пространственных данных Республики Татарстан» ДБУ (08.08.2022 № 1595/04) хатын күздә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында” 19.12.2015 № 3233-р карары (алга таба - № 3233-р Карар) белән урнаштырылган 22373 м. озынлыктагы, инвентарь номеры 54008, исәп номеры 16.50.2.2375 булган газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасын гамәлдә булуын туктатырга.

2. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендәге (“Инвентарь номеры 5933 булган газүткәргечнең саклау зонасы”) Татарстан Республикасы “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми мәйданы 91294 кв.м ± 106 кв.м рәвешендә территорияне куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләре урнашуның текстлы һәм график тасвирламасында күрсәтелгән белешмәләргә, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегенә туры китереп урнаштырырга.

3. Инвентарь номеры 54008 булган газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында өлешчә яки тулысынча газүткәргечнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. Территорияне куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләре урнашуның текстлы һәм график тасвирламасында күрсәтелгән белешмәләргә, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ әзерләнгән газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 3233-р карарына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.01.2017 № 107-р, от 22.06.2017 № 1378-р, от 13.07.2017 № 1608-р, от 29.08.2017 № 1977-р, от 28.09.2017 № 2191-р, от 22.09.2017 № 2155-р, от 22.08.2018 № 2563-р, от 31.08.2018 № 2653-р, от 05.12.2018 № 4140-р, от 25.06.2019 № 1970-р, от 07.08.2019 № 2419-р, от 05.11.2019 № 3520-р, от 21.01.2020 № 117-р, от 25.10.2021 № 3236-р, от 28.12.2021 № 4111-р, 14.06.2022 № 1741-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Казан ш. (Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары) территориясендә урнашкан 1 452,92119 км озынлыктагы, ЭПУ «Казаньгоргаз»ның әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү челтәрләре (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «РКЦ «Земля» АҖ, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зоналарына картасында (планында) булган белешмәләр нигезендә расларга.»;

1 нче кушымтада:

инвентарь номеры 54008 булган газүткәргечкә туры килгән юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «909 | 54008 | 8115 | Татарстан Республикасы, Казань ш., Совет районы | 22400 | түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=159. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=108. урта басымлы җир өсте газүткәргече; d=89. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=57. урта басымлы җир асты газүткәргече; d=630. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=57. урта басымлы җир асты газүткәргече; d=630. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=168. | 16-50.3-23.2001-1048.1 от 26.10.2001;» |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=40. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=76. урта басымлы җир асты газүткәргече; d=80. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=219. урта басымлы җир асты газүткәргече; d=325. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=150. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=50. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=100. түбән басымлы җир асты газүткәргече; d=114. түбән | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | басымлы жир асты газүткәргече; d=54. түбән басымлы жир асты газүткәргече; d=102. урта басымлы жир асты газүткәргече; d=600. түбән басымлы жир асты газүткәргече; d=273. урта басымлы жир асты газүткәргече; d=530. урта басымлы жир асты газүткәргече; d=63. | |

2 нче кушымтаны әлеге карарның кушымтасына туры кипереп тулыландырырга.

5. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Н.В.Захаровка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министрлыгың
22.08.2022 № _2447-р______
карарына кушымта

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «54008 | ТР, МО «Казань ш.» МБ, Совет районы, Гвардейская ур. | Милек | - | 16:50:060401:2012 | Торак пунктлар җирләре | 125,64 | ООО «Урсал» | Күпкатлы торак төзелеше (биек биналар); уртача биеклектәге торак төзелеше |
| 54008 | ТР, МО «Казань ш.» МБ, Совет районы, Гвардейская һәм А.Кутуй урамнары арасындагы кишәрлек | Милек | - | 16:50:060401:51 | Торак пунктлар җирләре | 467,00 | Өлешле милек; «Эссет Менеджмент» ЖЧҖ ышанулы идарә | җитештерү-склад биналары (код 6.0 – җитештерү эшчәнлеге)» |